| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЛЕБЕДИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЛЕБЕДИНО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕНЕҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с.Лебедино

**15.05.2023** **№9**

**Хайваннарны хуҗаларсыз кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итү гәвәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2019 № 1275 «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннар белән эшитү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру Тәртибен раслау турында» карары нигезендә, Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге чикләрендә хуҗасыз хайваннарны элек кегеяшәү урыннарына кайтаруты елаторган урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе хайваннарны хуҗаларсыз элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итү гәвәкаләтле затбулып тора.
3. Әлеге карарны гамәлдәге законнарга ярашлы рәвеш тәбастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Лебедино авыл җирлеге Башкарма**
**комитеты Җитәкчесе** **Ю.И.Тюкарев**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Лебедино авыл
Җирлеге башкарма
комитетының
15.05.2023 ел, №9
карарына кушымта

Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге чикләрендә хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Элеккегеяшәүурыннарынакайтарутыела (башка хайваннарга яки кешегә карата мотивациясе загрессивлык күрсәтмәгән хуҗаларсыз хайваннарны тоту урыны, хайваннар өчен приюта мондый хайваннарны приютта, тоту мөмкинлеге булмаган очракта стерильләштерү, билгеләү, исәпкәалу, карантин, дәвалау, вакцинация чаралары тәмамланганнан соң территорияләрдә һәм 500 метр ераклыктагы территорияләрдә:

-социаль өлкә учреждениеләре;

-сәламәтлек саклау объектлары;

- мәгариф учреждениеләре (мәктәпләр, балалар бакчалары);

-мәдәният объектлары;

-балалар уен һәм спорт мәйданчыклары;

- җәмәгать территорияләре (бакчалар, парклар, скверлар ,урамнар, торак пунктлар мәйданнары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары);

-масса күләм чаралар үткәрү өчен мәйданчыклар;

-стационар булмаган сәүдәо бъектларын урнаштыру урыннары, сәүдә нокталары территорияләре;

-зиратлар һәм мемориаль зоналар.